МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.12.2014 Казан шәһәре № 488

**Дәүләт лицензия контроле өлкәсендә техник экспертиза уздыру экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары тарафыннан контрольдә тоту чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» карарын үтәү йөзеннән **боерам:**

1. Расларга:

Кара, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсе экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Комиссиясе турындагы Нигезләмә (1 нче кушымта) (алга таба – Нигезләмә);

Кара, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре (2 нче кушымта).

2. Административ реформа мәсьәләләре Идарәсенең лицензияләү бүлеге башлыгы Н.Н. Горновскаяга әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад министры урынбасары А.Д. Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр** **А.А. Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
24.12.2014 488 номерлы
боерыгына кушымта1

**Кара, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсе экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Комиссиясе турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кара, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсе экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) комиссиясе (алга таба - Комиссия) дәгъва кылучылар тарафыннан лицензияләрне - үтәү, лицензиатлар тарафыннан кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендәге законнар таләпләре өлешендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә экспертларны (алга таба – экспертлар) аттестацияләү өчен төзелә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары тарафыннан контрольдә тоту чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» карарына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Комиссия эшчәнлегенең төп принциплары – объективлык..., хәбәрдарлык, бәйсезлек.

1.4. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыралар.

## 2. Комиссия вәкаләтләре

2.1. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

эксперт статусын алуга дәгъва кылучының квалификациясен тикшерү максатыннан квалификация имтиханын үткәрү;

квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча аттестация критерийларына дәгъва кылучының туры килүе яисә туры килмәве турында карар кабул итү.

2.2. Комиссия әгъзалары Комиссия рәисе раславына Комиссия составын һәм аның эш тәртибен үзгәртү турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

## 3. Комиссиянең составы һәм эш тәртибе

3.1. Комиссия Министрлык тарафыннан алты кешедән төзелә.

3.2. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия секретаре, Комиссиянең дүрт әгъзасы керә.

3.3. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, аның утырышларында рәислек итә, Комиссия эшен оештыра, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән Комиссиядә тавыш бирүдә катнаша, Комиссия карарлары беркетмәләренә кул куя.

3.4. Комиссия секретаре Комиссиянең эш башкаруын алып бара, комиссия утырышында көн тәртибе буенча чыгыш ясый, Комиссия карарлары беркетмәләрен төзи.

3.5. Комиссиянең төп эш формасы булып квалификация имтиханнары үткәрелә торган утырышлар тора.

3.6. Комиссия утырышларны аттестация турында гариза алган көннән 3 айдан да соңга калмыйча үткәрә.

3.7. Комиссия карары утырышта катнашучы әгъзаларның ачык тавыш бирү юлы, гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия, утырышта аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

3.8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия секретаре тарафыннан алып барыла һәм утырышны үткәрү көнендә Комиссия утырышында рәис тарафыннан имзалана.

## 4. Квалификация имтиханын үткәрү тәртибе

4.1. Квалификация имтиханын үткәрү датасы Комиссия утырышын үткәрү датасын билгеләргә 10 эш көне кала Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

4.2. Аттестацияне узу өчен дәгъва кылучы Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килүен раслый торган түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендәге форма буенча аттестация турында гариза;

б) югары техник белем турындагы дипломның күчермәсен;

в) паспортның яки шәхесне раслый торган башка документ күчермәсе;

г) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә металлургия җитештерүе, металл

ватыкларын эшкәртү өлкәсендә эш стажының булуын раслый торган башка документлар;

д) металлургия җитештерүе, металл ватыкларын эшкәртү, өстәмә белгечлекләр алу һәм күрсәтелгәнөлкәдә квалификация күтәрү өлкәсендә белем бирү хезмәтләрен алуны раслый торган булган башка документларның күчермәләре.

4.3. Әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән документлар дәгъва кылучы тарафыннан турыдан-туры тапшырыла яки тапшыру турында хәбәрнамә белән Министрлыкка заказлы почта аша яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4. Квалификация имтиханы әңгәмә формасында үткәрелә.

Квалификация имтиханын үткәрү барышында Комиссия әгъзалары дәгъва кылучының Министрлык тарафыннан тикшерү узган, квалификация имтиханын үткәрүгә рөхсәт ителгән документлары белән танышалар.

4.5. Комиссия дәгъва кылучының металлургия җитештерүе, металл ватыкларын эшкәртү өлкәсендәге законнар таләпләрен белү дәрәҗәсен, һөнәри эш тәҗрибәсе булуын билгели.

4.6. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча Комиссия дәгъва кылучының Нигезләмәнең 5 бүлегендә күрсәтелгән аттестация критерийларына туры килүе яисә туры килмәве турында дәлилләнгән карар кабул итә.

4.7. Квалификация имтиханы нәтиҗәсе, әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча аның аттестация критерийларына туры килүе турында карар кабул ителсә, дәгъва кылучыны аттестацияләү турында боерыкны бастырып чыгару өчен нигез булган Комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча аның аттестация критерийларына туры килмәве турында карар кабул ителсә яисә дәгъва кылучыквалификация имтиханына килмәсә, экспретны аттестацияләүдән баш тарту турында Комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.8. Дәгъва кылучыга әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктында күрсәтелгән кабул ителгән карар турында кабул ителгән көненнән алып 3 эш көне эчендә, тапшыру турында хәбәрнамә белән боерыкны заказлы почта аша җибәреп (тапшырып) яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәреп хәбәр ителә.

4.9. Экспертлар әлеге Нигезләмәнең 4.1-4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәр 5 ел саен яңадан аттестация узарга тиеш.

4.10. Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд тәртибендә, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы Россия Федерациясе законнары

нигезендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

## 5. Экспертларны аттестацияләү критерийлары

5.1. Эксперт аттестациясе алуга дәгъва кылучы, предприятиенең кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген алып баручы шәхси эшкуары, гамәлгә куючысы, җитәкчесе, башка вазыйфаи заты булырга тиеш түгел.

5.2. Соискатель тиеш:

а) югары техник белемгә ия булырга;

б) металлургия җитештерүе, металл ватыкларын эшкәртү өлкәсендә кимендә биш ел эш стажы булырга;

в) металлургия җитештерүе, металл ватыкларын эшкәртү өлкәсендәге законнар таләпләрен белергә;

г) металлургия җитештерүе, металл ватыкларын эшкәртү өлкәсендә тәҗрибә һәм һөнәри осталыкка ия булырга.

Кара, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсе экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы икътисад министрына

______________________________
(ФИА)

Экспертны аттестацияләү турында гариза

Мин, ____________________________________________
(Дәгъва кылучының ФИА)

кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы эксперты аттестациясен алу өчен квалификация имтиханына кертүне сорыйм.

Үзем турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм:
Яшәү урыны адресы ________________________________
Шәхесне раслый торган документ белешмәләре
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
Телефон номеры ___________________________________
Электрон почта адресы ______________________________
Почта адресы _____________________________________
ИНН_____________________________________________
Документлар кушымта итеп бирелә: ___________________
(документлар исемлеге)

___________________ ______________________________
(дата) (имза)

**Кара, төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре.**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр кара, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә дәүләт лицензия контроле өлкәсендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы экспертлары Реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели, шул исәптән Реестрга кертелә торган белешмәләрнең составын да билгели.

1.2. Реестрны төзү һәм алып бару Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының административ реформа мәсьәләләре идарәсенең электрон формада лицензияләү бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Реестр Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырыла: http://mert.tatarstan.ru/rus/Licensing.html.

## 2. Экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе

2.1. Реестрны төзү һәм алып бару экспертлар турында белешмәләрне Реестрга кертү, саклау, системалаштыру, белешмәләрне актуальләштерүне үз эченә ала.

2.2. Экспертлар турында белешмәләрне Реестрга кертү өчен Министрлыкның экспертны аттестацияләү, яңадан аттестацияләү, аттестацияләү гамәлләрен туктату турындагы карары нигез була.

2.3. Экспертлар турында белешмәләр әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көне эчендә Реестрга кертелә.

## 3. Реестрдагы мәгълүматлар

3.1. Реестрда түбәндәге белешмәләр бар:

а) язманың теркәү номеры;

б) эксперт турында белешмәләрне Реестрга кертү датасы;

в) физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

г) физик затның яшәү урыны адресы;

д) шәхесне раслый торган документ белешмәләре;

е) телефон номеры һәм электрон почта адресы (әгәр булса);

ж) салым түләүченең идентификацион номеры;

з) аттестация турында карар кабул итү номеры һәм датасы;

и) кабат аттестацияләү турында карар кабул итү номеры һәм датасы;

к) экспертны аттестацияләүне туктату турында карар кабул итү номеры һәм датасы;

л) экспертның квалификациясе, шул исәптән квалификация күтәрү, һөнәри яңадан әзерләү узуы турында белешмәләр;

м) экспертның белеме һәм эш тәҗрибәсе турында белешмәләр;

н) эксперт эшли торган яки хезмәт күрсәтү максатларында үзара бәйләнешне гамәлгә ашыра торган оешманың атамасы һәм урнашу урыны.

3.2. Реестрдагы мәгълүматлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматка кагылышлы белешмәләрдән тыш, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, юридик һәм физик затларга танышу өчен ачык булып тора.

3.2. Реестрдагы мәгълүматтан файдалануга мөмкинлек әлеге белешмәләрне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән тәэмин ителә.